| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУРТЫШ-ТАМАКСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**20.06.2022 ел** **№ 8**

Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә капиталь булмаган корылмалар булган гаражларны урнаштыру һәм инвалидларның яшәү урыны янында алар өчен техник яки башка хәрәкәт итү чараларын куеп тору тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 05 апрелендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 3936-1 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1.Кушымтада бирелә торган Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә капиталь булмаган корылмалар булган гаражларны урнаштыру һәм инвалидларның яшәү урыны янында алар өчен техник яки башка хәрәкәт итү чараларын кую тәртибен расларга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районының
Мортыштамак авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н.Һадиуллин

Җирле үзидарә органнары тарафыннан капиталь булмаган корылмалар булган гаражларны һәм инвалидларның яшәү урыны янында алар өчен техник һәм башка хәрәкәт итү чараларын куеп тору урынын урнаштыру схемаларын раслау тәртибе

1. Бу Тәртип дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә (алга таба - җир кишәрлекләре) капиталь булмаган корылмалар булган гаражларны (алга таба - гаражлар) һәм инвалидларның яшәү урыны янында алар өчен техник яки башка хәрәкәт итү чараларын куеп тору урынын (алга таба -куеп тору урыны) (алга таба икесен берьюлы кулланганда - объектлар) урнаштыру схемасын (алга таба - схема) эшләү, килештерү һәм раслау шартларын һәм чаралары исемлеген, шулай ук объектларны схемага кертү һәм схемадан төшереп калдыруны билгели.

2. Схема Татарстан Республикасындагы җирлекләрнең, шәһәр округларының җирле үзидарә органнары (алга таба - вәкаләтле орган) тарафыннан раслана торган гаражларны һәм куеп тору урыннарын урнаштыру урыны бирелгән документ булып тора.

Схемага шулай ук гаражлар һәм куеп тору урыннарын урнаштыру рөхсәт ителә торган урыннар да кертелә.

3. Схема җир законнары, шәһәр төзелеше эшчәнлеге, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану һәм дәүләт тарафыннан саклау, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге, янгын куркынычсызлыгы, юл хәрәкәте иминлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау, төзекләндерү өлкәсендә норматив хокукый актлар һәм бу Тәртип таләпләрен исәпкә алып эшләнә.

4. Схема вәкаләтле орган тарафыннан җир кишәрлекләрен инвентаризацияләү нәтиҗәләрен, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан алынган белешмәләрне, шулай ук физик затларның, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының объектны схемага кертү турындагы тәкъдимнәрен (алга таба - кызыксынучы зат, тәкъдим) исәпкә алып эшләнә.

Схемага шул исәптән «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 5 апрелендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән гаражлар, шулай ук әлеге федераль закон үз көченә кергән көнгә кадәр инвалидларга бирелгән куеп тору урыннары да керә.

Гараж схемага иң күбе биш елга кертелә. Инвалидлар өчен объектлар схемага чикләнмәгән срокка кертелә.

5. Объект түбәндәге очракларда схемага кертелмәскә тиеш:

а) схемага кертергә планлаштырыла торган объект торгларда яисә торглар үткәрмичә бирү эшләре башланган, шул исәптән сервитут, гавами сервитут билгеләү турында килешү төзү хакында, җир кишәрлеген яңадан бүлү турында килешү төзү хакында, дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җирләрне яки җир кишәрлеген файдалануга рөхсәтнамә бирү хакында гаризасы бирелгән, аукцион үткәрү турында, җир законнары нигезендә бирү максатларында территориянең кадастр планында җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында, җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында карары булган, җир кишәрлегенә карата сервитут, гавами сервитут билгеләү

турында килешү төзелгән, җир кишәрлеген яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалыгы булган җир кишәрлеге чикләрендә урнашканда;

б) чикләрендә объект урнаштырырга планлаштырыла торган җир кишәрлеге (җир кишәрлегенең бер өлеше) физик яки юридик затка бирелгәндә;

в) җир кишәрлегендә бүтән объектлар урнаштыруны килештерү турында элегрәк карар кабул ителгәндә;

г) чикләрендә объект урнаштырырга планлаштырыла торган җир кишәрлегенә (анда урнашкан биналарга, корылмаларга) карата суд тикшерүе һәм (яки) аның белән чиктәш җир кишәрлекләре чикләренә һәм (яки) мәйданына карата суд тикшерүе булганда;

д) объект урнаштырырга планлаштырыла торган җир кишәрлеге файдалану буенча билгеләнгән чикләүләр объектлар урнаштырырга рөхсәт итми торган территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрендә урнашканда;

е) чикләрендә объект урнаштырырга планлаштырыла торган җир кишәрлеге (җир кишәрлегенең бер өлеше) гомуми файдаланудагы территория чикләрендә урнашканда;

ж) чикләрендә объект урнаштырырга планлаштырыла торган җир кишәрлегенә гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре аша керү (үтү, бару) юлы булмаганда;

з) расланган җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрендә, тиешле муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү һәм карап тоту кагыйдәләрендә җир кишәрлегендә объектлар урнаштыру каралмаганда;

и) объектны урнаштыру федераль законнарда һәм башка норматив хокукый актларда (муниципаль норматив хокукый актларда) билгеләнгән тыюларны һәм чикләүләрне яисә башка затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга китергәндә.

6. Схема бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча эшләнә һәм текст һәм график өлешләрдән тора.

Схеманың текст өлешендә түбәндәге мәгълүмат чагылдырыла:

объектның төре (гараж/куеп тору урыны);

объектның урнашу урыны (якындагы күчемсез мөлкәт объекты адресына карата билгеләнә);

объектның мәйданы (кв.метр);

объект урнаштыру срогы.

Схеманың график өлеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 11 сентябрь, б-1805 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына кушымта булган картографик материалларны рәсмиләштерү буенча методик тәкъдимнамәләр нигезендә эшләнә.

7. Схеманы эшләү турында мәгълүмат вәкаләтле орган тарафыннан үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

8. Кызыксынучы затларның тәкъдимнәре схеманы эшләү турында мәгълүмат урнаштырылган көннән 30 эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

Тәкъдимдә җир кишәрлеге планында объектның сурәте, шулай ук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен билгеләнгән координатлар системасында объект чикләренең характерлы нокталары координатлары исемлеге һәм аның мәйданы турында белешмәләр бирелергә тиеш.
Бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән таләпләрнең берсен үтәмәү тәкъдимне караудан баш тарту өчен нигез булып тора.
Схема проектын эшләгәндә таләпләр бозылып бирелгән тәкъдимнәр исәпкә алынмый, бу турыда вәкаләтле орган тәкъдим кергән көннән 10 эш көне эчендә, тәкъдимне караудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, кызыксынучы затка хәбәр итәргә тиеш.

9. Вәкаләтле орган тәкъдимнәрне кабул итү срогы чыккан көннән 30 эш көне эчендә түбәндәге өлкәләрдә вәкаләтле структур бүлекчәләрдә килештерелә торган схема проектын эшли:

шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә;

җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә;

төзекләндерүне оештыру өлкәсендә;

уңайлы әйләнә-тирә мохитне тәэмин итү өлкәсендә;

халыкка транспорт хезмәте күрсәтү һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә;

халыкның тормыш эшчәнлеге иминлеген тәэмин итү өлкәсендә;

җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру өлкәсендә;

коммуналь-инженерлык инфраструктурасы өлкәсендә.

10. Бу Тәртипнең 9 пункты нигезендә килештерелгән схема проектында объектларны түбәндәге урыннарда урнаштырырга дип каралган очракта:

а) мәдәни мирас объектлары территорияләрендә яки аларны саклау зоналарында - схема проекты, мәдәни мирас объектлары әһәмиятенә (федераль, төбәк яки җирле әһәмияттәге) карап, мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә вәкаләтле орган белән килештерелергә тиеш;

б) Россия Федерациясе милкендәге җир кишәрлегендә - схема проекты Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасындагы һәм Ульяновск өлкәсендәге территориаль идарәсе белән килештерелергә тиеш;

в) Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегендә - схема проекты Татарстан Республикасы территориясендә мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы белән килештерелергә тиеш.

Әлеге органнар тарафыннан схема проектын килештерү срогы проект схемасы килештерүгә кергән вакыттан алып иң күбе 20 эш көне тәшкил итә.

Схема проектын килештерү, килештерүдән баш тарту, схема проектына карата кимчелекләр (тәкъдимнәр) язмача рәсмиләштерелә һәм вәкаләтле органга җибәрелә. Шул ук вакытта килештерүдән баш тарту нигезле булырга һәм анда баш тарту сәбәпләре күрсәтелергә тиеш.

11. Килештерелгән схема проекты вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында муниципаль норматив хокукый актлар проектларын җәмәгатьчелек белән тикшерү турында вәкаләтле органның

норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла. Җәмәгатьчелек белән тикшерү өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң, вәкаләтле орган 14 эш көне эчендә түбәндәге карарларның берсен кабул итә: схеманы раслый, схема проектын эшләп бетерүгә җибәрә яисә баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, объектны схемага кертүдән баш тарта.

12. Схема вәкаләтле орган карары белән раслана һәм норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шулай ук вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

13. Схемага үзгәрешләр кертү (объектларны схемага кертү яки объектларны схемадан төшереп калдыру) (алга таба - схемага үзгәрешләр кертү проекты) кызыксынучы затларның вәкаләтле органга җибәрелгән тәкъдимнәре нигезендә яки вәкаләтле орган инициативасы буенча гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган, бу Тәртипнең 3, 5, 6, 9, 10, 14 пунктларындагы таләпләрне исәпкә алып, схемага үзгәрешләр кертү проектын эшли.

Схемага үзгәрешләр керткәндә вәкаләтле орган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта схемага үзгәрешләр кертү проектын эшләү турында мәгълүмат урнаштыра.

Кызыксынучы затларның бу Тәртипнең 8 пункты таләпләрен исәпкә алып бирелгән тәкъдимнәре схемага үзгәреш кертү проектын эшләү турында мәгълүмат урнаштырылган көннән 30 эш көне эчендә кабул ителә.

Схемага үзгәрешләр кертүне раслау бу Тәртипнең 11, 12 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Объектны схемадан төшереп калдыруга бәйле рәвештә, схемага үзгәрешләр керткәндә бу Тәртипнең 10 пунктында каралган процедуралар башкарылмый.

14. Объектны схемадан төшереп калдыру түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

а) әгәр объектка карата схемага кертелгәннән соң алты ай эчендә ихтыяҗ булмаса;

б) вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге карар кабул ителгәндә:

объектны урнаштыру каралган җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗлары яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алу турында;

объектларны урнаштыру өчен җир кишәрлекләрен үз эченә алган территорияне комплекслы үстерү турында;

в) объектны урнаштыру каралган җир кишәрлеген законнар белән күздә тотылган тәртиптә кызыксынучы затка биргәндә;

г) әгәр объектны урнаштыру законнар таләпләренә туры килмәсә;

д) кызыксынучы зат объекттан баш тартканда;

е) Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{36-1}$ статьясындагы 2 пунктында каралган түләү ике һәм аннан күбрәк тапкыр билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырылмаганда.

Җирле үзидарә органнары тарафыннан капиталь булмаган корылмалар булган гаражларны һәм инвалидларның яшәү урыны янында алар өчен техник һәм башка хәрәкәт итү чараларын куеп тору урынын урнаштыру схемаларын раслау тәртибенә кушымта

Форма

______________________________________________

**(муниципаль берәмлек исеме)**

территориясендә капиталь булмаган корылмалар булган гаражларны һәм инвалидларның яшәү урыны янында алар өчен техник һәм башка хәрәкәт итү чараларын куеп тору урынын урнаштыру

| Т/с | Объектның төре (гараж/куеп тору урыны) | Гараж/куеп тору урыны адресы (урнашу урыны) | Гаражның/куеп тору урынының мәйданы, кв.метр | Гараж/куеп тору урыны урнашу срогы | Башка мәгълүматлар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |